**МИНИСТЕРСТВО ЛЕСНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ УРМАН ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

29.06.2022 № 354-осн

Казан ш.

Татарстан Республикасы территориясендә урман законнары бозылу нәтиҗәсендә урманнарга китерелгән зыянны исәпләп чыгару өчен чыгым нормативларын раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урман законнары бозылу нәтиҗәсендә урманнарга һәм алардагы табигать объектларына китерелгән зыянны каплау үзенчәлекләрен раслау турында» 2018 елның 29 декабрендәге 1730 номерлы карары нигезендә, урман законнары бозылу нәтиҗәсендә урманнарга, шул исәптән урман утыртмаларына яисә урман утыртмаларына кертелмәгән агачларга, куакларга һәм лианаларга (алга таба – урманнар) китерелгән зыян күләмен ачыклау максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы территориясендә урман законнары бозылу нәтиҗәсендә урманнарга китерелгән зыянны исәпләп чыгару өчен чыгым нормативларын расларга.

2. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урман законнары бозылу нәтиҗәсендә урманнарга һәм алардагы табигать объектларына китерелгән зыянны каплау үзенчәлекләрен раслау турында» 2018 елның 29 декабрендәге 1730 номерлы карарында билгеләнгән таксалар нигезендә, урман законнары бозылу нәтиҗәсендә урманнарга китерелгән зыян күләмен чәчкеннәр һәм кәлшәләр үстерүгә, урман культуралары, урман орлыкчылыгы һәм плюс агачларының вегетатив токымнарыннан плантацияләр, табигый шытып чыккан яшь үсентеләрне булдыруга һәм аларны карап тотуга, шытымнарны саклауга, территорияне (агач киселгән урыннарны) кисенте калдыкларыннан, көнкүреш һәм төзелеш калдыкларыннан чистартуга һәм аны алга таба куллану өчен яраклы торышка китерүгә, урман корылышы һәм урман хуҗалыгы билгеләрен ясауга һәм урнаштыруга, урман юлларындагы яки янгынга каршы билгеләнештәге юлларда җитешсезлекләрне бетерүгә, янгынга каршы минераллаштырылган полосалар коруга бәйле чыгымнар күләменнән чыгып исәпләгән очракта, хокук бозу вакытында гамәлдә булган, әлеге боерыкта билгеләнгән чыгым нормативлары кулланыла дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы вазыйфаи затларына, Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениеләренә – федераль

дәүләт урман контролен (күзәтчелеген), урман сагын гамәлгә ашыручы урманчылыкларга урман законнары бозылу нәтиҗәсендә урманнарга китерелгән зыян күләмен исәпләгәндә әлеге боерыкка таянып эш итәргә.

4. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы территориясендә урман законнары бозылу нәтиҗәсендә урманнарга китерелгән зыянны исәпләп чыгару өчен чыгым нормативларын раслау турында» 2020 елның 10 мартындагы 202-осн номерлы боерыгын көчен югалткан дип танырга.

5. Бу Боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча министрның беренче урынбасары И.Н.Зариповны җаваплы итеп билгеләргә.

Министр Р.Ә. Кузюров

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2022 елның 29 июнендәге 354-осн номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы территориясендә урман законнары бозылу нәтиҗәсендә урманнарга китерелгән зыянны исәпләп чыгару өчен чыгым нормативлары

| т/с | Эшләр төре | Үлчәү берәмлеге | Күләме | Чыгымнар, сум |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Юкка чыгарылган яки җимерелгән урман төзелеше билгесен әзерләү һәм урнаштыру | данә | 1,0 | 2470,17 |
| 2. | Юкка чыгарылган яки җимерелгән урман хуҗалыгы билгесен әзерләү һәм урнаштыру | данә | 1,0 | 1706,64 |
| 3. | Территорияне (агач киселгән урыннарны) чистарту һәм алга таба файдалану өчен яраклы хәлгә китерү | куб.метр | 1,0 | 151,37 |
| 4. | Территорияне (агач киселгән урыннарны) чистарту һәм алга таба файдалану өчен яраклы хәлгә китерү | гектар | 1,0 | 6054,91 |
| 5. | Чәчкеннәрне һәм кәлшәләрне 2 елга кадәр үстерү | данә | 1,0 | 3,11 |
| 6. | Чәчкеннәрне һәм кәлшәләрне 3 елга кадәр үстерү | данә | 1,0 | 3,85 |
| 7. | Ябык тамыр системасы белән кәлшәләр үстерү | данә | 1,0 | 15,57 |
| 8. | 3 яшькә кадәрге урман культуралары булдыру | гектар | 1,0 | 98137,76 |
| 9. | 4 яшьтән 5 яшькә кадәрге урман культуралары булдыру | гектар | 1,0 | 113430,62 |
| 10. | 6 яшьтән 10 яшькә кадәрге урман культуралары булдыру | гектар | 1,0 | 169910,87 |
| 11. | Агач кисү планлаштырылган урыннарда һәм киселгән урыннарда туфрак өслеген минераллаштыру юлы белән урманның табигый торгызылуына булышлык итү | гектар | 1,0 | 3011,76 |
| 12. | Урманның табигый торгызылуына булышлык күрсәтү чаралары белән шытым саклау | гектар | 1,0 | 6305,80 |
| 13. | Урман орлыкчылыгы плантациясе булдыру | гектар | 1,0 | 216507,85 |
| 14. | Урман орлыкчылыгы плантацияләрен карап тоту, карап тотуның һәр елы өчен | гектар | 1,0 | 30036,29 |
| 15. | Территорияне төзелмәләрдән, умарталардан чистарту һәм алга таба файдалану өчен яраклы хәлгә китерү | гектар | 1,0 | 121025,76 |
| 16. | Территорияне коммуналь-көнкүреш һәм сәнәгать калдыклары, көнкүреш һәм төзелеш калдыклары чүп-чарыннан арындыру | куб.метр | 1,0 | 1385,80 |
| 17. | Урман юлындагы җитешсезлекләрне бетерү | км | 1,0 | 41449,31 |
| 18. | Янгынга каршы билгеләнештәге юлдагы җитешсезлекләрне бетерү | км | 1,0 | 35074,25 |